РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2022 елның 9 феврале** **Чистай шәһәре** **№ 13/2**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Каргалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы белән, Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, ачык тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, 2021 елның 8 августындагы 1 номерлы каршылыкларны җайга салу буенча килештерү комиссиясе беркетмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Каргалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең кушымта итеп бирелә торган генераль планын расларга.
2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Каргалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планын Россия Федерациясе территориаль планлаштыру Федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырырга.
3. Әлеге карарны «Чистай хәбәрләре» газетасында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
башлыгы Д.А. Иванов